Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XI-7**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 маддәләре, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 маддәләре, “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 маддәсе нигезендә, 2021 елның 18 маендагы гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне исәпкә алып, “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Генераль планын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2021 елның
31 августындагы XI-7 номерлы
карары белән расланды

**ТАТИНВЕСТГРАЖДАНПРОЕКТ**
**баш территориаль проект-тикшеренү,**
**фәнни-җитештерү фирмасы**
**Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

**Территориаль планлаштыру турында Нигезләмә**

**Аңлатма язуы**

**Казан 2020**

| ГП | Состав проектной документации<br>Генеральный план Бетьковского сельского поселения<br>Рыбно-Слободского муниципального района РТ | | | |
|---|---|---|---|---|
| № раздела | Обозначение | Наименование | Инвентарный № | Примечание |
| **I.** | | **Генеральный план** | | |
| | | Том 1 | | |
| | ПЗ | Положение о территориальном планировании | | |
| | ГМ | Графические материалы | | |
| **II.** | | **Материалы по обоснованию генерального плана** | | |
| | | Том 2 | | |
| | ПЗ | Пояснительная записка | | |
| | ГМ | Графические материалы | | |
| | | 1. Архитектурно-планировочная организация | | |
| | | территории | | |
| | | 2. Социально-экономическое развитие территории | | |
| | | 3. Инженерная подготовка территории | | |
| | | 4. Инженерная инфраструктура | | |
| | | 5. Территории, подверженные риску | | |
| | | возникновения чрезвычайных ситуаций | | |
| | | Том 3 | | |
| | | Охрана окружающей среды | | |
| | ПЗ-ООС | Пояснительная записка | | |
| | ГМ-ООС | Графические материалы | | |

| Изм. | Кол.уч. | Лист | № док. | Подпись | Дата | Заказ № 5459 | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Нач. АПМ-5 | | Валидова А.З. | | | | Генеральный план Бетьковского сельского поселения Рыбно-Слободского муниципального района РТ | СТАДИЯ | ЛИСТ | ЛИСТОВ |
| ГАП | | Щербакова М.А. | | | | | ГП | | |
| Разработчик | | Баязитова Р.Н. | | | | Состав проектной документации | ГУП «Татинвестгражданпроект» | | |

## Содержание тома 1


| № п/п | Обозн. основн. комплект | Наименование | Инв. номер тома | Колич. страниц | Примечание |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Содержание тома 1: | | | |
| I | ПЗ | Положение о территориальном планировании | | | |
| II | | Графические материалы | | | |
| 1. | ГМ | Карта планируемого размещения объектов местного | | | |
| | | значения поселения М 1: 10000 | | | |
| 2. | ГМ | Карта границ населенных пунктов, входящих | | | |
| | | в состав поселения М 1:10000 | | | |
| 3. | ГМ | Карта функциональных зон поселения М 1:10000 | | | |


ЛИСТ

Заказ № 5459

# ЭЧТӘЛЕК

**ЭЧТӘЛЕК** ............ ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.
**КЕРЕШ** ............ ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.
**1. БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТУРЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТ** ............ ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.
**2. БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ БУЕНЧА ФЕДЕРАЛЬ, РЕГИОНАЛЬ ҺӘМ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ** ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА. ............ 9
2.1. ГОМУМИ ОЕШТЫРУ ЧАРАЛАРЫ
2.2. СӘНӘГАТЬ ҖИТЕШТЕРҮЕН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ............ **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
2.3. АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ............ **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
2.4. УРМАН КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР . **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
2.5. ТОРАК ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ............ **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
2.6. ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ СИСТЕМАСЫН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ............ **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
*2.6.1. Социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын үстерү* ***Ошибка! Закладка не определена.***
*2.6.2. Коммуналь хезмәт күрсәтү объектларын (зиратларны) үстерү* ............ ***Ошибка! Закладка не определена.***
2.7. ТУРИЗМ-РЕКРЕАЦИЯ СИСТЕМАСЫН ҮСТЕРҮ. ҖИРЛЕ ХАЛЫКНЫҢ ЯЛ ИТҮ УРЫННАРЫН ОЕШТЫРУ ............ **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
2.8. ТРАНСПОРТ-КОММУНИКАЦИЯ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ .... **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.**
2.9. БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТОРАК ПУНКТЛАРЫНЫҢ ЧИКЛӘРЕН БИЛГЕЛӘҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР **ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.** ............ 29
2.10. ИНЖЕНЕРЛЫК ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ............ 33
2.11. ТЕРРИТОРИЯНЕ ИНЖЕНЕРЛЫК ӘЗЕРЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ ............ 33
2.12. ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЧАРАЛАРЫ, ТАБИГЫЙ ҺӘМ ТЕХНОГЕН ХАРАКТЕРДАГЫ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘРНЕ КИСӘТҮ ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ............ 34

# КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең генераль планы проектлауга бирем нигезендә "Татинвестгражданпроект" ДУП тарафыннан эшләнде. Генераль план проектын эшләүгә заказчы булып Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тора.

Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең генераль планы – шәһәр төзелеше стратегиясен, тормыш эшчәнлеге мохитен булдыру шартлары, җирлек территорияләренең үсеш юнәлешләре һәм чикләре, җирлек составындагы торак пунктларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, территорияләрне функциональ зоналарга бүлү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, тарихи-мәдәни мирас объектларын һәм аеруча саклана торган табигать территорияләрен, экологик һәм санитария иминлеген саклауга шәһәр төзелеше таләпләрен билгели торган территориаль планлаштыру документы.

Генераль план аны тормышка ашыруның түбәндәге вакытлыча срокларына эшләнде:

Генераль планны гамәлгә ашыру буенча беренче нәүбәттәге чаралар билгеләнгән тәүге чират – 2025 елга чаклы.

Генераль планның барлык төп проект чишелешләре планлаштырылган исәп-хисап вакыты – 2040 елга чаклы.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 маддәсе нигезендә Бәтке авыл җирлегенең генераль планы проектына түбәндәгеләр керә:

**1 өлеш (раслана торган)** текст һәм график материаллар составында:

*Текст материаллары* – территориаль планлаштыруның максатларын һәм бурычларын, территориаль планлаштыру чаралары исемлеген һәм генераль планны тормышка ашыру этаплары буенча аларны үтәү эзлеклелеген үз эченә алган территориаль планлаштыру турында Нигезләмә.

*График материалларда* территориаль планлаштыру картасы бар.

**2 өлеш Проектны нигезләү материаллары.** Алар, текст һәм график материаллар составында эшләнгән авыл җирлегенең генераль планын раслау процессын килештерү һәм тәэмин итү өчен, территориаль планлаштыру тәкъдимнәрен нигезләү һәм аңлату максатларында эшләнә.

*Текст материаллары* җирлек территориясенең торышын, аны комплекслы үстерү проблемаларын һәм юнәлешләрен анализлауны, территориаль һәм пространство-планлаштыру үсешен нигезләүне, территориаль планлаштыру чаралары исемлеген, аларны тормышка ашыру этапларын, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу хәвефенең төп факторлары исемлеген үз эченә ала.

*График материалларда* генераль план Нигезләмәләрен дәлилләү схемалары бар.

Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең генераль планын эшләгәндә түбәндәге материаллар файдаланылды:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 февралендәге 134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемалары (Министрлар Кабинетының 09.07.2020 № 569 карары редакциясендә);

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 2 декабрендәге XXXI-4 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемалары (15.07.2016, 16.11.2016 еллардагы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән);

- Балык Бистәсе муниципаль районы һәм аның составына керүче Бәтке авыл җирлеге администрацияләре тарафыннан бирелгән рәсми мәгълүматлар.

# 1. БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТУРЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТ

Бәтке авыл җирлеге чиге "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә кабул ителде (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).

Бәтке авыл җирлеге Балык Бистәсе муниципаль районының төньякта Балыклы Чүкәй, төньяк-көнчыгышта Яңа Арыш, көнчыгышта Түбән Тегермәнлек һәм Олы Кульга, көньякта Троицкий Урай, көньяк-көнбатышта һәм көнбатышта Анатыш, төньяк-көнбатышта Шумково авыл җирлекләре территорияләре белән чикләнә.

Бәтке авыл җирлеге составына, югарыда күрсәтелгән закон нигезендә, Бәтке (административ үзәк), Дикое Поле, Кече Укмас, Яншык авыллары керә.

Бәтке авыл җирлегенең гомуми мәйданы 6991,05 га тәшкил итә, шул исәптән 250,5638 га торак пунктларның мәйданы, шулардан: Бәтке авылы – 88,8106 га, Дикое Поле авылы-42,9674 га, Кече Укмас авылы-46,5406 га, Яншык авылы – 72,2452 га.

Бәтке авыл җирлеге һәм Балык Бистәсе районы Татарстан Республикасының үзәк өлешендә, җитәрлек ресурс белән тәэмин ителгән (руда булмаган файдалы казылмалар, су, урман, җир ресурслары) булган, федераль һәм региональ автомобиль юллары уза торган уңайлы икътисади-географик урынны били.

Җирлек территориясе буенча Бәтке һәм Укмас елгалары ага. Җирлектәге төп объектлар: мөгезле эре терлек фермалары, ындыр табагы ("Логос" ҖЧҖ); вак таш карьеры ("Балык Бистәсе Агрохимсервис" ААҖ); 3 фельдшер-акушерлык пункты, 3 авыл мәдәният йорты, 2 китапханә, почта элемтәсе бүлекчәсе, полициянең участок пункты, кибетләр.

Бәтке авыл җирлегенең Татарстан Республикасының башка районнары, Россия Федерациясе төбәкләре белән транспорт элемтәсе хәзерге вакытта региональ яки муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юллары аша гамәлгә ашырыла.

# 2. БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ БУЕНЧА ФЕДЕРАЛЬ, РЕГИОНАЛЬ ҺӘМ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

## 2.1. Гомуми оештыру чаралары

Бәтке авыл җирлегенең үсеш юнәлешләрен билгеләгәндә Татарстан Республикасының, Балык Бистәсе муниципаль районының, Бәтке авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегияләре, региональ һәм федераль тармак программалары исәпкә алынды.

2015елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән "2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе" расланды.

Расланган стратегия кысаларында Балык Бистәсе муниципаль районы түбәндәге проектларны тормышка ашыру территориясе булып тора: "Идел-Кама агымы» экозонасы, "Татарстан Республикасының тиз йөрешле транспорт төрләрен булдыру", "Казан икътисадый зонасында калдыклар белән идарә итү".

## 1.2. Сәнәгать җитештерүен үстерү буенча чаралар

Генераль план белщн, беренче чиратта, түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

- авыл хуҗалыгы җирләре өчен 5,31 га мәйданлы территориянең бер өлешенең билгеләнгән функциясен өлешчә үзгәртеп Яншык авылыннан көньяктарак урнашкан карбонат тау токымнарын чыгару карьеры территориясен үзгәртеп төзү;
- Яншык авылыннан көньяктарак гомуми мәйданы 18,76 га булган файдаланылмый торган (гамәлдә булмаган) карьерлар территорияләрен авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртү (күчерү).

Таблица .2.2.1

*Бәтке авыл җирлегендә сәнәгать җитештерүен үстерү чаралары исемлеге*

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| 1 | Яншык авылыннан көньяктарак | Карбонат тау токымнарын чыгару карьеры | Авыл хуҗалыгы җирләре өчен 5,31 га җирне өлешчә үзгәртеп төзү | га | 13,0 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Яншык авылыннан көньяктарак | Гамәлдә булмаган карьерлар | Авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртү (күчерү). | га | 18,76 | - | | | |

## 1.2. Агросәнәгать комплексын үстерү чаралары

Генераль план белән беренче чиратта түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

-Яншык авылында гамәлдә булмаган МТП территориясен башка зоналарга үзгәртеп төзү;

-Яншык авылында гамәлдә булмаган ашлык склады территориясен башка зоналарга үзгәртеп төзү;

-Бәтке авылындагы җәйге лагерь территориясен башка зоналарга үзгәртеп кору;

-Яншык авылыннан көньяк-көнбатыштарак җәйге лагерь территориясен өлешчә авыл хуҗалыгы җирләре итеп үзгәртеп кору;

-Бәтке авылында гамәлдә булмаган МТП территориясен башка зоналарга үзгәртеп төзү.

Бәтке авыл җирлегенең агросәнәгать комплексын үстерү чаралары 2.3.1 нче таблицада күрсәтелгән.

Таблица 2.3.1

*Бәтке авыл җирлегендә агросәнәгать комплексын үстерү чаралары исемлеге*

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| 1 | Яншык авылы | МТП (гамәлдә түгел) | башка зоналарга үзгәртеп кору | га | 1,43 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Яншык авылы | Ындыр табагы (гамәлдә түгел) | башка зоналарга үзгәртеп кору | га | 0,88 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 3 | Бәтке авылы | җәйге лагерь | башка зоналарга үзгәртеп кору | га | 1,36 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 4 | Яншык авылыннан көньяк-көнбатыштарак | җәйге лагерь | авыл хуҗалыгы җирләре итеп 0,57 га мәйданлы территориянең бер өлешен үзгәртеп кору | га | 1,35 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 5 | Бәтке авылы | МТП (гамәлдә түгел) | башка зоналарга үзгәртеп кору | га | 6,73 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

**Урман комплексын үстерү чаралары**

Урман хуҗалыгы өлкәсендәге чаралар урманнарны яңадан торгызу, янгыннардан саклау, пычрану (шул исәптән радиоактив матдәләр) һәм башка тискәре йогынтыдан саклау, шулай ук зарарлы организмнардан саклау, шәһәр һәм торак пунктларның яшел зоналары мәйданнарын саклау һәм үстерү чараларын, шулай ук урман фонды һәм урман хуҗалыгы мәнфәгатьләренә кагылышлы башка өлкәләр эшчәнлегендәге кайбер чараларны үз эченә ала. Татарстан Республикасының барлык урманнары Россия Федерациясе милке булып торганга күрә, барлык чаралар да федераль әһәмияткә ия һәм федераль дәрәҗәдә контрольдә тотылырга тиеш.

Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы, Бәтке авыл җирлегенең генераль планы һәм башка программалар һәм документлар белән урман комплексын үстерү буенча исәп-хисап чорына кадәр чаралар каралмаган.

## 1.2. Торак инфраструктурасын үстерү буенча чаралар

Торак зоналарны оештыру, гамәлдәге торак фондын реконструкцияләү һәм яңа торак төзелеше мәйданчыкларын урнаштыру буенча тәкъдимнәр эшләү – генераль пландагы өстенлекле бурычларның берсе. Проект тәкъдимнәре шәһәр төзелеше анализы нәтиҗәләренә таяна: торак фондының техник торышы һәм төзелеш сыйфатламалары, торак төзелеше динамикасы һәм структурасы, территориянең экологик торышы.

Генераль план белән, беренче чиратта, торак төзелеше буенча түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

- Бәтке авылында 1,55 га мәйданлы территориядә гомуми мәйданы 0,7 мең кв. м булган торак (7 кишәрлек) урнаштыру;
- Кече Укмас авылында 1,03 га мәйданлы территориядә 0,8 мең кв. м мәйданлы торак (8 кишәрлек) урнаштыру;
- Яншык авылындагы 3,11 гектар территориядә гомуми мәйданы 2,1 мең кв.м (21 кишәрлек) торак урнаштыру.

Исәп-хисап буенча кирәкле торакны урнаштыру өчен Кече Укмас авылында буш территорияләр юк. Торак төзелешенә халыкның ихтыяҗы Яншык авылында торак төзелеше өчен тәкъдим ителә торган мәйданчыкта канәгатьләндерелергә мөмкин.

Таблица 2.5.1

*Бәтке авыл җирлегендә торак инфраструктурасын үстерү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | торак фонды | яңа төзелеш | га | - | 1,55 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| | | | | мең кв.м | - | 0,7 | | | |
| 2 | Кече Укмас авылы | торак фонды | яңа төзелеш | га | - | 1,03 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| | | | | мең кв.м | - | 0,8 | | | |
| 3 | Яншык авылы | торак фонды | яңа төзелеш | га | - | 3,11 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| | | | | мең кв.м | - | 2,1 | | | |

## 1.2. Халыкка хезмәт күрсәтү системасын үстерү буенча чаралар

### *2.6.1. Социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын үстерү*

**Мәгариф оешмалары**

Халыкның мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына ихтыяҗы беренче чиратта һәм исәп-хисап срогына 14 урынны тәшкил итәчәк.

Гомуми белем бирү оешмаларына даими халыкның ихтыяҗы беренче чиратта 34 урынны тәшкил итәчәк, исәп-хисап срогына – 30 урынны.

Генераль планда балаларны халыкның факттагы ихтыяҗына туры китереп Балык Бистәсе мәгариф оешмаларына йөртүне (ташуны) оештыру каралган.

**Медицина оешмалары**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 18 номерлы карары белән расланган (алга таба – Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы) 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы белән беренче чиратта Яншык авылында ФАПка капиталь ремонт ясау тәкъдим ителә.

**Мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре**

Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы белән түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

- исәп-хисап чорына Кече Укмас авылында мәдәният йортын капиталь ремонтлау;
- беренче чиратта Яншык авылы мәдәният йортын капиталь ремонтлау;
- исәп-хисап чорына Бәтке авылы мәдәният йортына капиталь ремонт ясау.

**Иҗтимагый үзәкләр**

Генераль план белән Бәтке авылында иҗтимагый үзәк төзү тәкъдим ителә (№1.11).

**Физик культура һәм спорт объектлары**

*Спорт заллары*

Беренче чиратта спорт залларына халыкның ихтыяҗы 141 кв. м ны тәшкил итәчәк, исәп-хисап чорына – 132 кв. м.

Генераль план нигезендә беренче чиратта иҗтимагый үзәк составында 144 кв. м мәйданлы (типовой проект нигезендә) спорт залы төзү тәкъдим ителә.

*Яссылык спорт корылмалары*

Беренче чиратта яссылык спорт корылмаларына ихтыяҗ – 786 кв. м, исәп – хисап чорына – 737 кв. м.

Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы белән Бәтке авылында исәп-хисап чорына универсаль спорт мәйданчыгы төзү тәкъдим ителә.

**Сәүдә предприятиеләре**

Генераль план нигезендә беренче чиратта Бәтке авылында иҗтимагый үзәк составында мәйданы 40 кв. м булган кибет төзү тәкъдим ителә.

Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы белән исәп-хисап чорына Кече Укмас авылында кибет төзү тәкъдим ителә.

**Җәмәгать туклануы предприятиеләре**

Генераль план нигезендә Бәтке авылында иҗтимагый үзәк бинасында 16 урынлык җәмәгать туклануы предприятиесе төзү тәкъдим ителә.

**Көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре**

Генераль план белән беренче чиратта Бәтке авылында иҗтимагый үзәк составында 2 эш урынына көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре төзү тәкъдим ителә.

**Административ-эшлекле объектлар**

Генераль план белән беренче чиратта түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

Бәтке авылы мәдәният йортында хакимият өчен булган бүлмәне үзгәртеп кору;

Бәтке авыл җирлеге хакимияте өчен Бәтке авылындагы иҗтимагый үзәк составында яңа бүлмә булдыру.

**Кредит-финанс учреждениеләре һәм элемтә бүлекчәләре**

Генераль план белән беренче чиратта түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

Бәтке авылы мәдәният йортында элемтә бүлеге өчен булган бүлмәне үзгәртеп кору;

Бәтке авылында иҗтимагый үзәк составында элемтә бүлекчәсе төзү.

Банк бүлекчәләрен һәм филиалларын урнаштыру күздә тотылмый.

**Полиция**

Генераль план белән беренче чиратта түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

Бәтке авылы мәдәният йортында полициянең участок пункты өчен булган бүлмәне үзгәртеп кору;

Бәтке авылында иҗтимагый үзәк составында полициянең участок пунктын төзү.

Бәтке авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү буенча чаралар 2.6.1 таблицасында тәкъдим ителгән.

Таблица 2.6.1

*Бәтке авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| *Медицина оешмалары* | | | | | | | | | |
| 1 | Яншык авылы | ФАП | капиталь ремонт | 1 сменада булучылар | 12,8 | - | - | + | Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| *Мәгариф оешмалары* | | | | | | | | | |
| 1 | Яншык авылы, Бәтке авылы, Кече Укмас авылы | Балык Бистәсе штп. балалар бакчаларына ташу | оештыру чарасы | - | - | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Яншык авылы, Бәтке авылы, Кече Укмас авылы | Балык Бистәсе штп. белем бирү мәктәпләренә ташу | оештыру чарасы | - | - | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| *ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| *Иҗтимагый үзәкләр* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк | яңа төзелеш | объект | - | 1 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *Мәдәни-ял итү учреждениеләре* | | | | | | | | | |
| 1 | Кече Укмас авылы | авыл мәдәният йорты | капиталь ремонт | урын | 130 | - | - | + | Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| 2 | Бәтке авылы | авыл мәдәният йорты | капиталь ремонт | урын | 100 | - | - | + | Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| 3 | Яншык авылы | авыл мәдәният йорты | капиталь ремонт | урын | 100 | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| *Административ-эшлекле объектлар* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | авыл мәдәният йорты составындагы администрация өчен бүлмәләр | үзгәртеп кору | объект | 1 | | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында Бәтке авыл җирлеге администрациясе | яңа төзелеш | объект | - | 1 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| *Спорт заллары* | | | | | | | | | |

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| 1 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында спорт залы | яңа төзелеш | кв.м идән мәйд. | - | 144 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| *Яссылык корылмалары* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | универсаль спорт мәйданчыгы | яңа төзелеш | объект | - | 1 | - | + | Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| *Сәүдә предприятиесе* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында сәүдә предприятиесе | яңа төзелеш | кв.м. сәүд. мәйд. | - | 40 | + | | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Кече Укмас авылы | сәүдә предприятиесе | яңа төзелеш | объект | - | 1 | - | + | Бәтке авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| *Җәмәгать туклануы предприятиеләре* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында җәмәгать туклануы предприятиесе | яңа төзелеш | урын | - | 16 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| *Көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре* | | | | | | | | | |

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| 1 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиесе | яңа төзелеш | эш урыны | - | 2 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| *Элемтә бүлекчәсе* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | авыл мәдәният йорты составында почта өчен бүлмә | үзгәртеп кору | объект | 1 | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында элемтә бүлекчәсе | яңа төзелеш | объект | - | 1 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| *Җәмәгать хокук тәртибен саклау* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке авылы | авыл мәдәният йорты составында полициянең участок пункты өчен бүлмә | үзгәртеп кору | объект | 1 | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Бәтке авылы | иҗтимагый үзәк составында полициянең участок пункты | яңа төзелеш | объект | - | 1 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

### *2.6.2. Коммуналь хезмәт күрсәтү объектларын (зиратларны) үстерү*

2040 елга Бәтке авыл җирлеге халкының зиратларга булган ихтыяҗы 0,09 га тәшкил итәчәк, шулай итеп, зиратлар белән тәэмин ителеш 32,44% булачак.

Генераль план нигезендә, Укмас елгасының һәм Бәтке елгасы кушылдыгының су саклау зонасына эләгүе сәбәпле, Кече Укмас авылыннан көнбатыштарак һәм Бәтке авылыннан төньяк-көнчыгыштарак зиратларның бер өлешен ябу тәкъдим ителә.

Бәтке авыл җирлегенең генераль планы нигезендә, зиратлар өчен җир төзелеше документациясен территориянең функциональ кулланылышына туры китерү тәкъдим ителә, аерым алгагда, зиратка дип җир кишәрлеге өчен "сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона җирләре, иминлек һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр" җирләре категориясенән "Ритуаль эшчәнлек" 12.1 рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләп кую.

Таблица 2.6.2

*Бәтке авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Торак пункт | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| 1 | Кече Укмас авылыннан көнбатыштарак | зират | 1,57 га мәйданлы өлешне ябу* | га | 3,84 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Бәтке авылыннан төньяк-көнчыгыштарак | зират | 0,12 га мәйданлы өлешне ябу* | га | 0,92 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

* зиратның ябыла торган өлешенең тулганлыгы буенча мәгълүматлар юк

## 1.3. Туризм-рекреация системасын үстерү. Җирле халыкның ял итү урыннарын оештыру

Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы белән “Балык Бистәсе районы халыкларының диннәре һәм традицияләре”дини-этнографик маршрутын оештыру тәкъдим ителә.

Бәтке авыл җирлегенең генераль планында рекреацион территорияләрне үстерү җирле халыкның ял итү зоналары буларак яшел утыртмалар системасын оештыру чараларын күздә тота.

Кешеләр ялы өчен уңайлы мөмкинлекләр тудыру, авыл торак пунктының йөзен яхшырту өчен кирәкле яшел утыртмалар системасын оештыру чаралары комплексы ике төп этапны күздә тота: гомуми файдаланудагы яшелләндерүне оештыру һәм чикләнгән файдалануны яшелләндерүне оештыру.

Гомуми файдаланудагы яшел утыртмалар оештыру (утырту) буенча чаралар – административ һәм җәмәгать биналары янында скверлар булдыру, көндәлек хезмәт күрсәтү үзәкләре булдыру, төп урамда бульвар урнаштыру, урамнарны яшелләндерү, чәчәк түтәлләре һәм газоннар урнаштыру.

Чикләнгән кулланылышта булган яшел утыртмаларны оештыру буенча чаралар – мәгариф һәм тәрбия объектлары территорияләрен һәм башка социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары территорияләрен яшелләндерү (өйтүр бакчалары урнаштыру, җиләк-җимеш һәм декоратив агачлар, куаклар утырту, чәчәклекләр урнаштыру).

Гомуми белем бирү оешмалары территорияләрен яшелләндерү алар территориясенең кимендә 50 % ын күздә тота. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары территорияләрен яшелләндерү төзелештән азат булган территориянең кимендә 50% ын тәшкил итәргә тиеш.

Моннан тыш генераль план белән исәп-хисап чорына су объектларын төзекләндерү тәкъдим ителә.

Туризм-рекреация системасын үстерү буенча чаралар исемлеге 2.7.1 таблицасында күрсәтелгән.

Таблица 2.7.1

*Бәтке авыл җирлегендә туризм-рекреацион системасын үстерү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Торак пункт, урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Ис.-хис. вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке АҖ | "Балык Бистәсе районы халыкларының диннәре һәм традицияләре"дини -этнографик маршруты | Маршрутны оештыру | маршрут | - | 1 | + | + | Балык Бистәсе МРның территориаль планлаштыру схемасы |
| *ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке ав.,Дикое Поле ав., Кече Укмас ав., Яншык ав. | гомуми файдалану урынын яшелләндерү | яшел утыртмалар системасын оештыру | - | - | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Бәтке АҖ | Сабантуй бәйрәме уздыру урыны | төзекләндерү (уңайлылык булдыру) | объект | 1 | - | + | | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 3 | Бәтке АҖ | су объектлары | Иҗтимагый рекреацион зоналар төзеп яр буе полосасын һәм аңа якын территорияне төзекләндерү | | | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

## 1.3. Транспорт-коммуникация инфраструктурасын үстерү

Транспорт-коммуникация инфраструктурасын үстерү чаралары исемлеге 2.8.1 нче таблицада бирелгән.

Таблица 2.8.1

*Бәтке авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын үстерү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *РЕГИОНАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| *Автомобиль юллары* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке АҖ | "Балык Бистәсе – Яншык" – Кече Укмас" | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 3,1 | - | + | - | ТР ТПС |
| 2 | Бәтке АҖ | "Балык Бистәсе – Яншык" | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 7,3 | - | + | - | ТР ТПС |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| *Автомобиль юллары* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке АҖ | "М-7 "Волга" – Шумково – Балык Бистәсе" – Дикое Поле" | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 3,1 | - | + | - | Балык Бистәсе МРның территориаль планлаштыру схемасы |
| 2 | Бәтке АҖ | "М-7 "Волга" – Балыклы Чүкәй" – Олы Укмас" – Кече Укмас | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 1,3 | | | | Бәтке авыл җирлегенең ге-нераль планы * |
| 3 | Бәтке АҖ | Кече Укмас зиратына килү юлы | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 0,1 | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең ге-нераль планы * |
| 4 | Бәтке АҖ | Бәтке зиратына килү юлы | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 0,3 | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы * |

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| 5 | Бәтке АҖ | Яншык авылы зиратына килү юлы | асфальт-бетон өслек урнаштыру | км | 0,6 | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы * |
| *ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | | |
| *Урам-юл челтәре* | | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке АҖ | урам-юл челтәре | асфальт-бетон өслек урнаштыру | - | 16,5 | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

* чараны тиешле дәрәҗәдәге документларга һәм/яки программаларга керткәндә

## 1.3. Бәтке авыл җирлеге торак пунктларының чикләрен билгеләү буенча чаралар

Россия Федерациясе Җир кодексының 84 маддәсендәге 1 өлешенең 1 пункты нигезендә торак пунктларның чикләрен билгеләү яки үзгәртү тиешле муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләрен чагылдыра торган шәһәр округының, җирлекнең генераль планын раслау яисә үзгәртү булып тора.

“Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында” 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) җир кишәрлекләрен торак пунктлар чикләренә кертү яки торак пунктлар чикләреннән чыгару җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында торак пунктлар яисә җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү яки мондый җирләр составындагы җирләрне яисә җир кишәрлекләрен торак пунктлар җирләренә күчерү булып тора.

Шулай итеп, 2010 елның 16 июнендәге 14-4692-ГЕ номерлы Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең хаты нигезендә, әгәр муниципаль берәмлекнең генераль планын раслау процедурасы бозылмаган булса, генераль планны раслау турындагы акт җирләрне яисә җир кишәрлекләрен күчерү турындагы акт булып тора.

2012 елда Бәтке авыл җирлегенең генераль планы эшләнгән, ул Бәтке авыл җирлеге Советының 2012 елның 6 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында килештерү процедурасын узмаган һәм, димәк, гамәлдән чыгарылырга тиеш.

Хәзерге вакытта Бәтке авыл җирлеге генераль планының яңа проекты эшләнә.

Торак пунктлар өчен гамәлдәге чикләр сыйфатында кадастр кварталлары чикләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте Идарәсе мәгълүматлары буенча “торак пунктлар җирләре” категориясендә җир кишәрлекләре чикләре буенча уздырылган чикләр кабул ителде.

Бәтке авыл җирлегенең генераль планы белән торак пунктларның чикләрен үзгәртү тәкъдим ителми.

## 2.10. Инженерлык инфраструктурасын үстерү чаралары

**Таблица 2.10.1**

*Су белән тәэмин итү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |
| 1 | Кече Укмас ав. | Артезиан скважинасы | Яңа төзелеш | данә | 1 | + | | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Бәтке ав. | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Капиталь ремонт | км | 3,0 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 3 | Дикое Поле ав. | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Капиталь ремонт | км | 1,5 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 4 | Кече Укмас ав. | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Капиталь ремонт | км | 2,5 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 3 | Яншык ав. | Су белән тәэмин итү челтәрләре | Капиталь ремонт | км | 1,5 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 4 | Су белән тәэмин итү системасы | Су куллануны исәпкә алу узеллары | Оештыру | данә | 3 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

Таблица 2.10.2

*Канализация буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |
| 1 | Авыл җирлеге территориясе | Канализациянең автоном системасы | Яңа төзелеш | данә | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

Таблица 2.10.3

*Калдыклар белән эш итү инфраструктурасы буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |
| 1 | Авыл җирлеге территориясе | - | Территорияне планлы-даими санитар чистарту | данә | 1 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Авыл җирлеге территориясе | Контейнерлар | Оештыру | данә | 12 | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

Таблица 2.10.4

*Җылылык белән тәэмин итү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке ав. | БМК для общественного центра | Яңа төзелеш | данә | 1 | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

Таблица 2.10.5

*Газ белән тәэмин итү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |
| 1 | Бәтке ав. | Югары басымлы газ бүлү челтәрләре | Яңа төзелеш | км. | - | + | - | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

Таблица 2.10.6

*Электр белән тәэмин итү буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның атальшы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| 1 | Авыл җирлеге территориясе | Трансформатор подстанциясе (ТП) | Реконструкция | кВА | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |
| 2 | Авыл җирлеге территориясе | Электр тапшыру линияләре | Реконструкция | км. | - | + | + | Бәтке авыл җирлегенең генераль планы |

Таблица 2.10.7

*Зәгыйфь ток челтәрләре буенча чаралар исемлеге*

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның атальшы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| *ҖИРЛЕ (РАЙОН) ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ЧАРАЛАР* | | | | | | | | |
| Чаралар юк | | | | | | | | |

## 2.11. Территорияне инженерлык әзерләү чаралары

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Егәрлек | | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | гамәл дәге | яңа (өстәмә) | Беренче чират (2025 елга чаклы) | Исәп-хисап вакыты (2026-2040 еллар) | |
| **Җирле әһәмияттәге чаралар** | | | | | | | | | | |
| 1 | Җирлек территориясе | | Хәтәр табигать процесслары күренешләренә мониторинг | Оештыру | | | | + | + | Генераль план |
| 2 | Җирлек территориясе | | Район территориясен хәтәр табигый процесслардан саклау буенча чаралар эшләү | Оештыру | | | | + | + | Генераль план |

## 2.12. Гражданнар оборонасы чаралары, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның аталышы | Чараның төре | Үлч. берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру вакыты | | Чара чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 1 чират | Исәп-хисап вакыты | |
| *Җирле әһәмияттәге чаралар* | | | | | | | | | |
| 1 | Җирлек территориясе | Сөйләмле сирена җайланмасы (РСУ) | Хәбәр итү системасын булдыру | Оештыру, яңа төзелеш | данә | 2 | + | + | Генераль план |
| 2 | Җирлек территориясе | Янгын пирсы | Янгын пирсы төзелеше | Яңа төзелеш | данә | 2 | + | + | "2014-2024 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү" дәүләт программасы (ТР МК ның 2013 елның 2 ноябрендәге 837 номерлы карары) |
| 3 | Җирлек территориясе | | Хәтәр табигать процесслары күренешләренә мониторинг | Оештыру | | | + | + | Генераль план |
| 4 | Җирлек территориясе | | Территорияне хәтәр табигый процесслардан саклау буенча чаралар эшләү | Оештыру | | | + | + | Генераль план |